| ГЛАВА<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**29.01.2018** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 01-03-2017** |

Зеленодольск муниципаль районында «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча комиссия нигезләмәсенә һәм составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган программа нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2010 елның 5 февралендәге 19 номерлы «Зеленодольск муниципаль районында «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча комиссия турында»гы карарына 1 нче һәм 2 нче кушымталарына үзгәрешләр кертергә, аларны әлеге карарга 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 17 июнендәге 01-126 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

**А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының

__________________ № _______________

карарына
1 нче кушымта

# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАШКА ТЕЛЛӘР ТУРЫНДА» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ БУЕНЧА КОМИССИЯ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Зеленодольск муниципаль районында «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча комиссия (алга таба - Комиссия) Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы каршындагы даими эшләүче орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларына, әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең составы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының карарлары белән раслана һәм үзгәрә. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

4. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр була:

- Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр белән хезмәттәшлекне тәэмин итү;

-Зеленодольск муниципаль районында Татарстан Республикасы законнарын 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында”, 2013 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында”, 2004 елның 11 октябрендәге 52-ТРЗ номерлы “2004-2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасын раслау турында”, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы “2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү турында” Дәүләт программасын раслау турында"

карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 маендагы 366-ТРЗ номерлы “2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү турында” Татарстан Республикасы Дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында" карарлары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 1 апрелендәге 204 номерлы “2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү турында” Татарстан Республикасы Дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында" карарлары (алга таба – чаралар планы) гамәлгә ашыру буенча ел саен чаралар планын төзү;

- чаралар планын үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итү;

- үз компетенцияләренә кертелгән мәсьәләләр буенча Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, предприятиеләргә, оешмаларга һәм учреждениеләргә консультатив һәм методик ярдәм күрсәтү.

5. Түбәндәге бурычларны гамәлгә ашыру максатларында Комиссия:

- җирле һәм республика тәҗрибәсен өйрәнү, анализлау һәм гомумиләштерү эшен оештыра, беренче чиратта хәл ителергә тиешле мәсьәләләрне билгели;

- Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан, предприятие, оешма һәм учреждениеләрдән кергән тәкъдимнәрне һәм киңәшләрне карый;

- үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр белән хезмәттәшлек итә;

6. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль предприятиеләрдән һәм учреждениеләрдән кирәкле материаллар алырга;

- Комиссия утырышларында Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча хәбәрләрне һәм тәкъдимнәрне тыңларга;

- үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле карарлар кабул итәргә.

- Комиссия эшчәнлеге юнәлешләре буенча эксперт һәм эшче комиссияләр, төркемнәр оештырырга.

7. Комиссия утырышлары Комиссия утырышында кабул ителә һәм аның рәисе тарафыннан раслана торган Эш планы нигезендә үткәрелә. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.